Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Яңа Иштирәк авыл җирлегенең
Яңа Иштирәк торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Яңа Иштирәк авыл җирлеге Яңа Иштирәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, саны 18 яшькә җиткән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санының 30%ыннан артмаган халыктан, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

ритуал хезмәтләрен оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:
-Яңа Иштирәк авылы Шоссейная урамында зиратны койма белән тоту

«РИЗА» «КАРШЫ»

соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 464 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 236.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 236 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Яңа Иштирәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Яңа Иштирәк авыл җирлеге Яңа Иштирәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, саны 18 яшькә җиткән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санының 30%ыннан артмаган халыктан, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә

билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

ритуал хезмәтләрен оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

-Яңа Иштирәк авылы Шоссейная урамында зиратны койма белән тоту сораулары буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Үзәк урам, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
"Яңа Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Мәүлетова